СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Узәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35. E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

**Урта Аты авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**24.09.2018** **№ 67**

Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«Сез 2019 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру(урам яктырту) | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру<br>(урам яктырту) - урам утларын алыштыру һәм урнаштыру<br>Түбән Аты авылы<br>Урта Сәрдә авылы<br><br>- каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча җыючы урыннарны карап тоту, чүп-чарны трактор белән тыгызлау; торак пунктларда<br>Түбән Аты авылы<br>Урта Сәрдә авылы<br><br>- Клачы авылында мотопомпа сатып алу; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - Түбән Аты, Урта Аты (һәр торак пунктта берәр янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.<br>- Урта Сәрдә авылында янгын савытын сатып алу һәм урнаштыру. |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларында арата юл эшчәнлеге | - Түбән Аты,Урта Сәрдә, Урта Аты, Клачи авылларында юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш җәю. - юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш түшәү |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http:pravo.tatarstan.r) гражданнар күплəп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында. : ТР, Арча районы , Түбән Аты авылы , Үзәк урамы, 37 йорт; ТР, Арча районы, Урта Сәрдә авылы, Үзәк урамы, 70 йорт; ТР, Арча районы, Кылачы авылы, Аяк җиеме урамы, 16

Урта Аты авыл
җирлеге башлыгы Батталова Р.Х